Татарстан Республикасы Законы

**“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) икенче абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацта “әйләнә-тирә табигать мохите” сүзтезмәсеннән “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

в) дүртенче абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

г) җиденче абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

д) унынчы абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

“Җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклауга бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итәргә мөмкин.”;

3) 5 статьяда “табигать” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 16 мае
№ 17-ТРЗ